| «Рассмотрена» | «Согласована» | «Утверждаю» |
| --- | --- | --- |
| Руководитель ШМО<br>_________ /______________ /<br>Протокол №____<br>от «___» _________ 20_ | Заместитель директора по УВР МБОУ «СМСОШ имени В.Ф.Тарасова»<br>_________ /______________ /<br>«___» _________ 20__г. | Директор МБОУ «СМСОШ имени В.Ф.Тарасова»<br>________ /______________ /<br>Приказ № ______<br>от «___» _________ 20__г. |

**Рабочая программа**
**по родной (татарской) литературе для 5 класса**

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Старомокшинская средняя общеобразовательная школа
имени В.Ф.Тарасова» Аксубаевского муниципального района
Республики Татарстан

Мирзяновой Назии Сантбурхановны,
учителя татарского языка и литературы
первой квалификационной категории.

Рассмотрена и принята на заседании
педагогического совета.
Протокол № ___от ________ августа

Срок реализации: 2018-2019 учебный год

**Аңлатма язуы**

5 нче сыйныф өчен туган тел әдәбиятыннан эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

- Положением о рабочей программе учебных предметов , курсов, в соответствии с ФГОС МБОУ «Старомокшинская СОШ им.В.Ф.Тарасова» , утвержденным приказом от 29.08.2018 г. № 175

-Учебным планом МБОУ «Старомокшинская СОШ им.В.Ф.Тарасова» на 2018-2019 учебный год , утвержденным приказом от 29.08.2018 г № 168, календарным учебным графиком , утвержденным приказом от 29.08.2018 г №171

- Основной образовательной программы основного общего образования МБОУ «Старомокшинская СОШ им.В.Ф.Тарасова»

Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 5 нче с-ф. Ике кисәктә. 1,2 нче кисәкләр / Ф. Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина; [рәссамы Фәридә Ризаева]. – Казан: "Мәгариф – Вакыт" нәшр., 2014., Татарстанның Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслек.

**5 нче сыйныфта туган тел әдәбияты елга 35 атнага, 35 сәгатькә исәпләнә, сәгатьләр күләме атнага 1 сәгать.** Предмет буенча арадаш аттестация эше ел ахырында мәктәпнең төп белем программасының календарь графигына туры китереп үткәрелә.

База дәрәҗәсе
Юнәлеше – урта (тулы) гомуми белем бирү
Программаның үтәлеше – 1ел

## ТУГАН ТЕЛ ӘДӘБИЯТЫНА ӨЙРӘТҮНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, күпмилләтле илебезгә карата ярату хисләре, татар әдәбиятына һәм башка халыклар әдәбиятына, мәдәниятенә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;
- төрле мәгълүмат чараларын танып-белү һәм аралашу мәсьәләсен хәл иткәндә (сүзлекләр, энциклопедия, Интернет ресурслар һәм башкаларны) куллану;
- активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең белән идарә итүгә юнәлдерелгән белем һәм күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру, әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү.

### Метапредмет нәтиҗәләре

"Әдәбият" курсын өйрәнүнең метапредмет нәтиҗәләре булып, универсаль уку-укыту гамәлләре формалаштыру санала (УУГ).

**Регулятив УУГ (РУУГ):**

- мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру;

- проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, материалны төзү, үз фикереңне раслау өчен дәлилләр сайлый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- уку проблемасын чишү өчен план төзү;
- шушы план нигезендә эш оештыру, үз эшчәнлегенең максатка ирешүдә ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булуын күзәтү;
- укытучы бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү.

**Танып белү УУГ (ТБУУГ):**

- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләү, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны укый белү (төп текст, астөшермә һәм башкалар), өстәмә материалларны таба һәм тиешле урында куллана белү;
- укуның төрле формаларыннан файдалану (аңлап уку, өстән-өстән, эчтәлекне аңлап);
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү; үзенә кирәкле мәгълүматны төрле формада бирелгән чыганаклардан туплау (тулы текст, өзек, иллюстрация, схема);
- бер мәгълүматны икенче төрле итеп үзгәртә алу (план төзү, таблица, схема);
- укылган әсәрнең эчтәлеген (яки ишеткәнне), текстка якын итеп, кыскача сайлап сөйли белү;
- әдәбиятны музыка, рәсем сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны танырга өйрәтү; әдәбиятны тел белеме белән бәйләп, әдәби әсәр теленең үзенчәлекләрен, әсәр стилен җиткерү;
- татар әдәбиятын рус әдәбияты, башка халыклар әдәбиятлары белән бәйләп укытып, әдәбиятлар арасындагы уртак проблемаларны, уртак кыйммәтләрне күрсәтү аша, дөнья культурасы белән танышу;
- сүзлекләр, белешмә материаллардан файдалану;
- бәхәсләшү, үз фикерен дәлилләү, анализ ясау, йомгаклау;
- әдәбиятны тарих, җәмгыять белеме, экология предметлары белән бәйләп, дөнья яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру.

**Коммуникатив УУГ (КУУГ):**

- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен тексттан өземтәләр китереп дәлилли белү;
- бер фикер кабул иткәнче, төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- күмәк эш вактында, бигрәк тә фикер агышлары төрле булганда, бер фикергә килә белү;
- укылган, тыңланган әсәрләр буенча сораулар бирә алу;
- үз эшен контрольдә тоту, иптәшләренә ярдәм итү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;
- башкаларны тыңлый, кирәк булганда үз фикерләрен үзгәртә алу;
- иптәшләре каршында төрле темаларга чыгыш ясау, бергәләп эшләгәндә бердәм карар кабул итә белү;
- текст буенча сораулар куя белү.

**Туган тел әдәбияты укытуның предмет нәтиҗәләре**

- сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
- классик әдипләрнең (К.Насыйри, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил һ.б.) биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;

- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү; әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү; укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һәм башкалар аша эзләү.

## ПРЕДМЕТНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Федераль базис укыту планында каралганча, 5 нче сыйныфта туган тел әдәбиятын өйрәнүгә атнасына 1 сәгать исәбеннән елга 35 сәгать бирелә, бу Татарстан Республикасының базис укыту планына туры килә.

Укучылар урта сыйныфларда халык авыз иҗаты әсәрләренең төрле жанрларын өйрәнә башлап, борынгы, XVII, XVIII, XIX, XX йөз әдәбиятларыннан иң яхшы әсәрләр белән, язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән танышалар. 5 нче сыйныфта 4 нче сыйныфта укыганнарга нәтиҗә ясала, әдипләрнең биографияләре тирәнтен өйрәнелә, яңа темалар, проблемалар белән таныштырыла, укыганны тирәнрәк аңларга, төрле белешмә әдәбиятны кулланырга өйрәтелә. Сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә, бәйләнешле сөйләмнәрен, иҗади эш күнекмәләрен ныгытуга махсус рубрикалар бирелә.

Программаның эчтәлеге түбәндәге бүлекләрдән тора һәм әлеге бүлекләр буенча үтәлергә тиешле минимумны чагылдыра.

### Кереш

**Ибраһим Гази**нең китап турындагы **“Үзе бер могҗиза”әсәре**н укып фикер алышу. Дәреслекнең төзелеше (структурасы – тышлык, титул бите, форзац, шартлы билгеләр, эчтәлек, дәреслекне төзүчеләр: автор, рәссам, редактор, корректор, нәшир һ.б.) белән танышу.

Китап турында мәкаль, табышмаклар, кызыклы мәгълүматлар.

### Халык авыз иҗаты

**Фольклор** – күмәк халык авыз иҗаты. Фольклорның кече жанрлары. Балалар фольклоры (табышмак, такммак, санамыш, мәсәл һ.б.) турында кабатлау. Бишек җырлары (халык авыз иҗаты белән беррәттән, авторлар иҗат иткән бишек җырларын да өйрәнү).

**Әдәбият теориясе.** Халык авыз иҗаты.Фольклор.

### Татар халык әкиятләре

Халык авыз иҗаты төре буларак әкиятләр. Тылсымлы, хайваннар турындагы, тормыш-көнкүреш әкиятләре. Әкият геройлары үрнәгендә шәфкатьлелек, миһербанлылык тәрбияләү.

**“Ак байтал”** – тылсымлы әкият. Ат турында мәкальләр. Атка мәдхия.

Тылсымлы әкиятләрнең поэтикасы. Тылсымлы әкиятләрдә фантастик элементлар.

**“Үги кыз”** – тормыш-көнкүреш әкияте. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәт. Яхшылыгыңның да, начарлыгыңның да үзеңә кире кайтуы. Бумеранг принцибы. Кыерсытылган ятимнең, яхшылыкның җиңеп чыгуы, шәфкатьле, миһербанлы булуның җимешләрен татуы.

**“Хәйләкәр төлке”** – хайваннар турындагы әкият.

**“Солдат боткасы”, “Өч каләм”, “Камыр батыр”, “Кәтән Иваныч”** әкиятләренең кайсы төргә керүен һәм нинди билгеләре буенча төркемләнүен ачыклау. Әкиятләрдә ярдәмчеләр.

**Әдәбият теориясе.** Әкият. Әкият төрләре. Әкиятнең төзелеше. Даими эпитетлар. Гипербола турында төшенчә. Чагыштырулар. Кабатлаулар. Инверсия. Әкияттә башлам, бетем, кульминация, чишелеш, төенләнеш, үстерелеш элеменлары. Халык әкиятләренең вариативлыгы.

**Халык иҗаты белән рухланып**

Халык иҗаты әсәрләренә таянып, язучылар иҗат иткән мәсәлләр, Г.Тукай һәм Ә. Исхак, Г.Тукай һәм И.Крылов, Г.Тукай һәм Г.Шамуков язган исемдәш мәсәлләр. Уртак һәм аермалы яклары. Мәсәлләрне сәнгатьле уку.

**Әдәбият теориясе.** Мәсәл жанры, читләтеп әйтү, сюжеты. Мәсәлләрдә хикәяләү, мораль. Бу жанрда иҗат итүче язучылар. Мәсәл белән мәкальнең уртак яклары.

**Хәзинә. Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләре**

**Кол Гали** турында белешмә. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән данлыклы **“Кыйссаи Йосыф”** әсәре турында. Поэмадан өзекләр уку. Әсәрнең сюжеты. Әсәрне өйрәнгән галимнәр. “Кыйссаи Йосыф” нигезендә иҗат ителгән пьеса һәм балет либреттосы. Башка язучыларның дастанга ияреп язылган әсәрләре турында төшенчә бирү.

**Шәүкәт Галиев**нең Кол Галигә багышланган шигыре.

**Казан ханлыгы әдәбияты үрнәкләре**

**Мөхәммәдьяр** турында белешмә. **“Нуры содур” поэмасы**ннан өзек (шигъри хикәят) уку. Хикәятнең мәгънәсенә игелекле эш-гамәлләр һич тә юкка чыкмавы, ә бәлки артыгы белән кире үзеңә кайтуы салыну.

**XIX йөз әдәбияты**

**Каюм Насыйри,** тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру*. **“Патша белән карт”*, “Бай һәм хезмәтче”, “Аңгыралык бәласе”** әсәрләренең халык авыз иҗатына нигезләнеп язылуы.

**Әдәбият теориясе.** Кысалы кыйсса, тартмалы композиция турында төшенчә бирү. Аларның аермасын аңлату.

**“Әбүгалисина”.** Белем алуның әһәмияте. Күңеле яхшылыкта булып, халыкка ярдәм итәргә теләгән Әбүгалисина һәм игезәге Әбелхарисның белем алырга омтылышлары. Тормыш юлларының аерылу сәбәпләре.

Каюм Насыйри музее.

**XX йөз башы татар әдәбияты**

**Габдулла Тукай.** Шагыйрьнең тормыш юлы турында кыскача белешмә*. **“Су анасы”*, “Эш беткәч уйнарга ярый”әсәрләре.** Тукайның бала психологиясен сурәтләве, балаларга белем һәм тәрбия бирүгә мөнәсәбәте. Б.Рәхмәтнең **“Эш беткәч” шигыре** белән уртак һәм аермалы якларын күзәтү.Язучыларның бөек шагыйрь турындагы фикерләре.

**Әдәбият теориясе.** Поэма турында төшенчә.Әкият-поэма. Аның әкият һәм поэма белән аермалы һәм уртак яклары. Кырлайдагы Тукай музее. Нәзыйрә жанры турында төшенчә.

**XX йөз татар әдәбияты**

**Галимҗан Ибраһимов.** Әдипнең тормыш юлы турында кыскача белешмә*. **“Яз башы”*, “Фагыйлә”хикәяләре.** Туган як табигатенең матурлыгы, аның белән хозурлану темаларының күтәрелүе һәм сәнгатьчә хәл ителеше.

**Әдәбият теориясе.** Хикәя, әдәби образ турында төшенчә.

**Муса Җәлил.** Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача белешмә*. **“Алтынчәч” либреттосы**ннан арияләр тексты. Либреттодан өзекләр уку.

**Әдәбият теориясе:** ария, либретто, строфа турында төшенчә, лирик герой.

**Сугыш чоры әдәбияты**

**Муса Җәлил.** Шагыйрьнең сугыш чорында язылган **“Кызыл ромашка”, “Җырларым”, “Бүреләр” шигырьләре.** Сугыш китергән фаҗига. Җиңүгә ышаныч. Үлемсезлек.

**Әдәбият теориясе.** Баллада жанры.
**Харис Якупов**ның **“Хөкем алдыннан” картинасы.** БСҮ
Муса Җәлил музейлары.
**Рафаэль Мостафин**ның шагыйрнең балачак елларын чагылдырган **“Балыкчы Муса” хикәясе.** Җәлил турында язучылар фикерләре.
**Фатих Кәрим.** Шагыйрьнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. “**Кыр казы”*, “Ватаным өчен”, “Сөйләр сүзләр бик күп алар...” шигырьләре.** Ватан азатлыгы өчен көрәшкән солдат батырлыгы. Сагыну хисләренең бирелеше.
**“Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл” әкият-поэмасы**. Әкияттә хайваннар образының бирелеше. Юмор хисе. Фатих Кәрим турында – язучылар.
**Гадел Кутуй.** Әдипнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. **“Сагыну” нәсере.** Туган илен азат итүдә катнашкан солдат образы. Аның туган ягын, Ватанын сагынуы, җиңәчәгенә ныклы ышанычы.
**Әдәбият теориясе.** Нәсер турында төшенчә.
**Абдулла Алиш.** Язучының тормыш юлы турында кыскача белешмә. **“Килделәр” хикәясе.** Сугыш вакытында базга яшеренгән кешеләрнең фашистларга нәфрәте. Бала психологиясенең бирелеше.
**Сибгат Хәким.** Шагыйрьнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. **“Колын” шигыре.** Сугышның хайваннарга да китергән фаҗигасе. Сибгат Хәким турында язучылар фикере. Сибгат Хәким музее.
**А. Пластов**ның **“Фашист самолеты очып үтте” картинасы. Л.Леронның “Фашист очып үтте” шигыре.** Әдәбият һәм сәнгать берлеге.

**Сугыштан соңгы чор әдәбият**

**Ренат Харис. “Ветеран дәфтәрләр” шигыре.** Сугыш чоры язмалары, истәлекләре. Аларның бүгенге көндә әһәмияте.
**Фатих Хөсни.** Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә.**“Чыбыркы”* хикәясе.** Һөнәр сайлау проблемасы. Авыл кешеләре хезмәте. Ата белән бала, күршеләр, малайлар арасындагы мөнәсәбәт. Бала характерының формалашуы.
**Роберт Әхмәтҗанов.** Шагыйрьнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. **“Солдатлар” шигыре.** Сугыш яраларының онытылмавы. Мәңгелек утның батырларга дан җырлавы. Тирән хисле шигырьләрнең җырга әверелүе.
**Нәби Дәүли.** Тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. **“Бәхет кайда була?”* шигыре.** Хезмәт яраткан кешенең бәхетне табуы. Кайсы чорда яшәсәң дә, хезмәтнең, тырышлыкның роле. **“Кар нинди җылы” хикәясе.** Өлкәннәр һәм балалар арасындагы мөнәсәбәт. Кечкенә балаларның да зурлар арасындагы мөнәсәбәтләргә битараф булмавы. Бәхетле булу өчен, әни генә түгел, әти дә кирәклеге. Бала психологиясенең бирелеше.
**Фәнис Яруллин.** Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. **“Зәңгәр күлдә Ай коена”* әкияте.** Яхшылыкка каршы яхшылык белән җавап бирү.Эчке матурлыкның ямьсезлекне җиңүе. **“Бөтенесе кирәк” шигыре.** Без – табигать баласы. Табигатьнең серле матурлыгы. Кешенең табигать өчен җаваплылыгы.
**Резеда Вәлиеваның “Бәхет” шигыре.** Бәхет төшенчәсе. Аның киң кырлылыгы. Туган илеңдә уку, эшләү, чыныгу – чын бәхет.

**Туган ил, туган як**

**Нәкый Исәнбәт.** Әдипнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. **“Туган ил” шигыре.** Туган як турында картиналар. **Нәҗип Мадьяров.** Тормыш юлы турында кыскача белешмә. **“Сиңа кайттым, гүзәл туган җирем” шигыре. Сибгат Хәким. “Бер горурлык хисе”, “Башка берни дә кирәкми” шигырьләре.**
**Фоат Садриев. “Тургай ни дип җырлый?” хикәясе.** Сабан тургаеның моң-зары, шатлык-куанычлары. Балага биргән киңәшләре. Туган ягына мәхәббәт белән сугарылган җырлары.
**Эльмира Шәрифуллина. “Татарстан шуннан башлана” шигыре.** Яшәгән төбәгең, республикаң белән горурлану, Ватанга карата патриотик хисләр тәрбияләү. **Гөлшат Зәйнәшева.** “Үз илемдә” шигыре. Ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү. **Резеда Вәлиева.**

Шагыйрьнең тормыш юлы турында кыскача белешмә. **“Табигать баласына” шигыре.** Р.Вәлиева турында - каләмдәшләре. **Мөдәрис Әгъләмов.** Тормыш юлы турында кыскача белешмә. **“Матурлык минем белән”* шигыре.** М.Әгъләмов турында – каләмдәшләре. Матурлык турында сөйләшү. **Гамил Афзал. “Туган җиреңнән китмә” шигыре.** Патриотик хисләр тәрбияләү. **Разил Вәлиев. “Туган телдә дәшсәм генә” шигыре.** Милли патриотизм хисләре тәрбияләү.

**Кадыйр Сибгатуллин. “Шишкин наратлары” шигыре. Иван Шишкинннның “Нарат урманы” картинасы.**

**Тәрҗемә әсәрләр**

**Андрей Платонов. “Ягъфәр бабай” хикәясе*** (Ф.Хәсәнова тәрҗемәсе). Сугыш чоры авылы тормышы. **Джовани Родари. “Әбинең кошчыклары” хикәясе** (Зөлфәт тәрҗемәсе). Баланың ата-ана алдында җаваплылыгы, мәңгелек бурычы. **Антуан де Сент Экзюпери. “Нәни принц” әсәре** (Р.Вәлиев тәрҗемәсе). Үсмер психологиясе.

**Шагыйрь һәм язучылар иҗатында юмор**

**Алмаз Гыймадиев. “Телефонлы кәҗә”, “Интернетта ALF”, “Дианаларда кунакта” хикәяләре.** Туган телдә матур татарча сөйләм. Милли гадәтләр һәм заманчалык каршылыгы. **Ләбиб Лерон. “Зөһрә кыз – безнең авылдан” хикәясе, “Песи булсаң иде” шигыре.** Үсмер психологиясе. Юмор, ирония. **Роберт Миңнуллин. “Уйлап табучы”, “Мин әгәр ике булсам” шигырьләре.** Бала психологиясе. **Шәүкәт Галиев. “Борау”, “Эш кушып булмый” шигырьләре. Рафис Корбан. “Үзем” шигыре. Фәнис Яруллин. “Җыр калдырыйк” шигыре.**

**Әдәбият теориясе.** Юмор, ирония, эпиграф, пародия.

**Сыйныфтан тыш уку өчен әсәрләр**

**“Кәтән Иваныч” әкияте.**
**ГабдуллаТукай.** “Эш беткәч уйнарга ярый” шигыре.
**Антуан де Сент** Экзюпери.“Нәни принц” әсәре.
**Рафаэль Мостафин.** “Балыкчы Муса” хикәясе.

**Бәйләнешле сөйләм үстерү**

Китап дигән могҗиза.
Бишек җырлары.
“Эш үткәч, үкенүдән файда юк” темасы сөйләшү.
Әсәргә миниатюр рецензия язу. Каюм Насыйри музеена сәяхәт.
“Хөкем алдыннан” картинасы буенча сочинение.
“Сугыш узган җирдә” картинасы буенча әңгәмә.
Л.Лерон “Фашист очып үтте” шигыре.
Шишкин наратлары.

**Ятлау өчен әсәрләр**

**Габдулла Тукай** “Су анасы” әсәре.
**Сибгат Хәким** “Бер горурлык хисе” шигыре.
**Фатих Кәрим** “Сөйләр сүзләр бик күп алар...” шигыре.
**Нәби Дәүли** “Бәхет кайда була?” шигыре.
**Шәүкәт Галиев** “Борау” шигыре.
**Мөдәрис Әгъламов** “Матурлык минем белән” шигыре.
**Эльмира Шәрифуллина** “Бишек җыры” шигыре.

**Минимум**

К.Насыйри. «Патша белән карт»
Г.Тукай. «Су анасы»
Г.Ибраһимов. «Яз башы»
М.Җәлил. «Алтынчәч»
Ф.Кәрим. «Кыр казы»
Ф.Хөсни. «Чыбыркы»
Ф.Яруллин. «Зәңгәр күлдә ай коена»

М.Әгъләмов. «Матурлык минем белән»
Н.Дәүли. «Бәхет кайда була?»

**** Минимумга кергән әсәрләр * белән күрсәтелде*

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| № | Төп темалар | Сәгать саны | Уку-укыту эшчәнлеге |
|---|---|---|---|
| 1. | Кереш. Халык авыз иҗаты. | 2 | Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау ясау, рус халык авыз иҗаты белән чагыштырып, мисаллар китерү. |
| 2. | Татар халык әкиятләре. | 5 | Әкият турында белем алу. Әкиятләрнең хайваннар турында, тылсымлы, тормыш-көнкүреш төрләре булуын аеру. Әкиятләрне укып чыгу һәм терәк сораулар буенча анализлау, гомумиләштереп, нәтиҗәләр чыгару. Әкияттәге уңай һәм тискәре образларны табу, аларга хас сыйфатларны билгели белү. |
| 3. | Халык иҗаты белән рухланып. | 1 | Халык иҗаты әсәрләренә таянып, язучылар иҗат иткән мәсәлләр, Г.Тукай һәм Ә. Исхак, Г.Тукай һәм И.Крылов, Г.Тукай һәм Г.Шамуков язган исемдәш мәсәлләр. Уртак һәм аермалы якларын билгеләү. |
| 4. | Хәзинә. Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләре. | 1 | Борынгы әдәбиятның үзенчәлеген аера белү. Сайлап алып уку, укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне бәяләү. Әсәрне аңлату, сөйләү, әңгәмә, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару. |
| 5. | Казан ханлыгы әдәбияты үрнәкләре. | 1 | Казан ханлыгы әдәбияты үрнәкләре белән танышу. Язучыларның иҗаты турында сөйли белү. Хикәят буенча сораулар бирә белү. |
| 6. | XIX йөз әдәбияты. | 2 | Шушы чорга караган әдәби әсәрне аңлату, сөйләү, әңгәмә, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару, план төзү, кыскача эчтәлеген сөйләү. |
| 7. | XX йөз башы татар әдәбияты. | 1 | Сайлап алып уку, укыганны анализлый белү, үз фикереңне дәлилләр табып исбатларга өйрәнү. Әңгәмә, сөйләү, образларга телдән бәяләмә бирү, сүзлек эше, анализ. |
| 8. | XX йөз татар әдәбияты. | 3 | Бу чор әсәрләрен уку һәм эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү. |
| 9. | Сугыш чоры әдәбияты. | 5 | Сугыш чоры әсәрләрен уку һәм эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү. Авторларның тормыш һәм иҗаты турында сөйли белү. Рәсемннәр буенча эш, төп детальләргә игътибар итеп, аның эчтәлеген сөйләү, нәтиҗә ясау. Видео, презентацияләр карау. |
| 10. | Сугыштан соңгы чор әдәбият. | 5 | Сугыштан соңгы чор әсәрләрен уку һәм эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү. Образларга телдән һәм язма бәяләмә бирү. Авторларның тормыш һәм иҗаты турында сөйли белү. Рәсемннәр буенча эш, төп детальләргә игътибар итеп, аның эчтәлеген сөйләү, нәтиҗә ясау. Видео, презентацияләр карау. |
| 11. | Туган ил, туган як. | 3 | Туган ягыбызгы мәхәббәт белән сугарылган җырлар белән танышу. Туган як турында картиналар карау. Язучыларның тормыш юлы турында кыскача белешмә туплау. |
| 12. | Тәрҗемә әсәрләр. | 1 | Рус һәм дөнья әдәбияты үрнәкләрен татар әдәбияты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | әсәрләре белән чагыштыру, охшаш һәм аермалы якларын билгеләү. Сүзлек өстендә эш, эчтәлек буенча фикер алышу. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау. |
| 13. | Шагыйрь һәм язучылар иҗатында юмор. | 2 | Сатира һәм юмор төшенчәләрен аңлата белү, мисаллар китерү. Татар әдәбиятында сатира һәм юморның урынын билгеләү. Сүзлек өстендә эш, эчтәлек буенча фикер алышу. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау. |
| 14. | Сыйныфтан тыш уку | 1 | Әсәрләрне уку һәм эчтәлеге буенча фикер алышу, укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне бәяләү. Әсәрне аңлату, сөйләү, әңгәмә, сорау кую, нәтиҗәләр чыгару. |
| 15. | Бәйләнешле сөйләм үстерү. | 2 | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, нәтиҗәләр чыгару, анализ ясау. |
| | **Барлыгы** | **35** | |

Белем дәрәҗәсен тикшерү төрләре

| | 1 чирек | 2 чирек | 3 чирек | 4 чирек | Еллык |
|---|---|---|---|---|---|
| Сәгатьләр саны | 8 | 8 | 10 | 9 | 35 |
| Сыйныфтан тыш уку | - | - | 1 | 1 | 4 |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү | - | 1 | 1 | 1 | 8 |

Туган тел әдәбиятыннан еллык арадаш аттестация эше еллык йомгаклау билгесе итеп куела.

## ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Темалар | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| **Халык авыз иҗаты - 2 сәгать** | | |
| 1. | Татар халык авыз иҗаты. | 1 |
| 2. | Татар халык авыз иҗатында әкиятләр. | 1 |
| **Татар халык әкиятләре - 5 сәгать** | | |
| 3. | “Ак байтал” әкияте. | 1 |
| 4. | “Ак байтал” әкиятендә тылсым көче. | 1 |
| 5. | «Үги кыз» әкияте. | 1 |
| 6. | «Хәйләкәр төлке», «Солдат балтасы» әкиятләре. | 1 |
| 7. | “Камыр батыр” әкияте. | 1 |
| 8. | “Өч каләм”, “Кәтән Иванович” әкиятләре. | 1 |
| **Халык иҗаты белән рухланып - 1 сәгать** | | |
| 9. | Мәсәлләр. Г.Тукай һәм Ә.Исхак мәсәлләре. | 1 |
| **Хәзинә. Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләре - 1 сәгать** | | |
| 10. | Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре. | 1 |
| **Казан ханлыгы әдәбияты үрнәкләре - 1 сәгать** | | |
| 11. | Мөхәммәдьяр иҗаты. | 1 |
| **XIX йөз әдәбияты үрнәкләре - 2 сәгать** | | |
| 12. | Каюм Насыйри иҗаты. «Патша белән карт» әсәре*. | 1 |
| 13. | К. Насыйриның “Әбүгалисина” әсәрендә гыйлемлелек проблемасы. | 1 |
| **XX йөз башы татар әдәбияты үрнәкләре - 1 сәгать** | | |
| 14. | Г.Тукай – татар халкының бөек шагыйре. “Су анасы” әкияте*. | 1 |
| **XX йөз татар әдәбияты үрнәкләре - 3 сәгать** | | |
| 15. | Г. Ибраһимов “Яз башы” әсәре*. | 1 |
| 16. | Г.Ибраһимов. “Фагыйлә” хикәясе, хикәя жанры. | 1 |
| 17. | М. Җәлил. “Алтынчәч” либреттосыннан өзек*. | 1 |
| **Сугыш чоры әдәбияты – 5 сәгать** | | |
| 18. | М.Җәлил. “Җырларым”, “Кызыл ромашка” шигырьләре. | 1 |
| 19. | Муса Җәлил музейларына сәяхәт. | 1 |
| 20. | **БСҮ**. “Хөкем алдыннан картинасы буенча сочинение. | 1 |
| 21. | **СТУ.** Р. Мостафин. “Балыкчы Муса” әсәре. | 1 |
| 22. | Ф. Кәрим. “Кыр казы” шигыре*. | 1 |
| 23. | Г.Кутуй. “Сагыну” нәсере. | 1 |
| 24. | А. Алиш. “Килделәр” хикәясе. | 1 |
| **Сугыштан соңгы чор әдәбияты – 5 сәгать** | | |
| 25. | Ф. Хөсни. “Чыбыркы” хикәясе*. | 1 |
| 26. | Н.Дәүли. “Бәхет кайда була?” шигыре*. | 1 |
| 27. | Н.Дәүли. “Кар нинди җылы” хикәясе. | 1 |
| 28. | Фәнис Яруллин. “Зәңгәр күлдә Ай коена” әкияте*. | 1 |
| 29. | Р. Әхмәтҗанов. “Солдатлар” шигыре. | 1 |
| **Туган ил, туган як турында – 3 сәгать** | | |
| 30 | **БСҮ.** Н.Исәнбәт. “Туган ил” шигыре, туган як турында картиналар. Р.Вәлиева. “Табигать баласы” шигыре | 1 |
| 31 | Фоат Садриев. “Тургай ни дип җырлый?” әсәре. | 1 |
| 32 | М.Әгъләмов “Матурлык минем белән” шигыре*. | 1 |
| **Тәрҗемә әсәрләр – 1 сәгать** | | |
| 33 | А.Платонов. “Ягъфәр бабай” әсәре*. **С.т.у. Антуан де Сент** Экзюпери.“Нәни принц” әсәре. | 1 |

| Шагыйрь һәм язучылар иҗатында юмор - 2 сәгать | | |
|---|---|---|
| 34 | А.Гыймадиев. “Дианаларда кунакта” хикәясе. Еллык арадаш аттестация эше. | 1 |
| 35 | Л.Лерон. “Зөһрә кыз – безнең авылдан” хикәясе. | 1 |

*Кушымта*

## Календарь- тематик план

| № | Темалар | Сәгатьләр саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| **Халык авыз иҗаты - 2 сәгать** | | | | |
| 1. | Татар халык авыз иҗаты. | 1 | 04.09 | |
| 2. | Татар халык авыз иҗатында әкиятләр. | 1 | 11.09 | |
| **Татар халык әкиятләре - 5 сәгать** | | | | |
| 3. | “Ак байтал” әкияте. | 1 | 21.09 | |
| 4. | “Ак байтал” әкиятендә тылсым көче. | 1 | 28.09 | |
| 5. | «Үги кыз» әкияте. | 1 | 05.10 | |
| 6. | «Хәйләкәр төлке», «Солдат балтасы» әкиятләре. | 1 | 12.10 | |
| 7. | “Камыр батыр” әкияте. | 1 | 19.10 | |
| 8. | “Өч каләм”, “Кәтән Иванович” әкиятләре. | 1 | 26.10 | |
| **Халык иҗаты белән рухланып - 1 сәгать** | | | | |
| 9. | Мәсәлләр. Г.Тукай һәм Ә.Исхак мәсәлләре. | 1 | 09.11 | |
| **Хәзинә. Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләре - 1 сәгать** | | | | |
| 10. | Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре. | 1 | 16.11 | |
| **Казан ханлыгы әдәбияты үрнәкләре - 1 сәгать** | | | | |
| 11. | Мөхәммәдьяр иҗаты. | 1 | 23.11 | |
| **XIX йөз әдәбияты үрнәкләре - 2 сәгать** | | | | |
| 12. | Каюм Насыйри иҗаты. «Патша белән карт» әсәре*. | 1 | 30.11 | |
| 13. | К. Насыйриның “Әбүгалисина” әсәрендә гыйлемлелек проблемасы. | 1 | 07.12 | |
| **XX йөз башы татар әдәбияты үрнәкләре - 1 сәгать** | | | | |
| 14. | Г.Тукай – татар халкының бөек шагыйре. “Су анасы” әкияте*. | 1 | 14.12 | |
| **XX йөз татар әдәбияты үрнәкләре - 3 сәгать** | | | | |
| 15. | Г. Ибраһимов “Яз башы” әсәре*. | 1 | 21.12 | |
| 16. | Г.Ибраһимов. “Фагыйлә” хикәясе, хикәя жанры. | 1 | 11.01 | |
| 17. | М. Җәлил. “Алтынчәч” либреттосыннан өзек*. | 1 | 18.01 | |
| **Сугыш чоры әдәбияты – 5 сәгать** | | | | |
| 18. | М.Җәлил. “Җырларым”, “Кызыл ромашка” шигырьләре. | 1 | 25.01 | |
| 19. | Муса Җәлил музейларына сәяхәт. | 1 | 1.02 | |
| 20. | **БСҮ**. “Хөкем алдыннан картинасы буенча сочинение. | 1 | 8. 02 | |
| 21. | **СТУ.** Р. Мостафин. “Балыкчы Муса” әсәре. | 1 | 15.02 | |
| 22. | Ф. Кәрим. “Кыр казы” шигыре*. | 1 | 22.02 | |
| 23. | Г.Кутуй. “Сагыну” нәсере. | 1 | 01. 03 | |
| 24. | А. Алиш. “Килделәр” хикәясе. | 1 | 15. 03 | |
| **Сугыштан соңгы чор әдәбияты – 5 сәгать** | | | | |
| 25. | Ф. Хөсни. “Чыбыркы” хикәясе*. | 1 | 22.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 26. | Н.Дәүли. “Бәхет кайда була?” шигыре*. | 1 | 05.04 | |
| 27. | Н.Дәүли. “Кар нинди җылы” хикәясе. | 1 | 12.04 | |
| 28. | Фәнис Яруллин. “Зәңгәр күлдә Ай коена” әкияте*. | 1 | 19.04 | |
| 29. | Р. Әхмәтҗанов. “Солдатлар” шигыре. | 1 | 26.04 | |
| **Туган ил, туган як турында – 3 сәгать** | | | | |
| 30. | **БСҮ.** Н.Исәнбәт. “Туган ил” шигыре, туган як турында картиналар. Р.Вәлиева. “Табигать баласы” шигыре. | 1 | 03.05 | |
| 31. | Фоат Садриев. “Тургай ни дип җырлый?” әсәре. | 1 | 10.05 | |
| 32. | М.Әгъләмов “Матурлык минем белән” шигыре*. | 1 | 10.05 | |
| **Тәрҗемә әсәрләр – 1 сәгать** | | | | |
| 32. | А.Платонов. “Ягъфәр бабай” әсәре*.<br>**С.т.у. Антуан де Сент** Экзюпери.“Нәни принц” әсәре. | 1 | 17.05 | |
| **Шагыйрь һәм язучылар иҗатында юмор - 2 сәгать** | | | | |
| 34. | А.Гыймадиев. “Дианаларда кунакта” хикәясе. Еллык арадаш аттестация эше. | 1 | 17.05 | |
| 35. | Л.Лерон. “Зөһрә кыз – безнең авылдан” хикәясе. | 1 | 24.05 | |